**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «23» октябреннән №49-377

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары турында» 2013 елның 10 апрелендәге 22-148 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номкрлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары турында» 2013 елның 10 апрелендәге 22-148 номерлы карарына (2013 елның 10 июлендәге 24-158 номерлы, 2014 елның 7 августындагы 35-203 номерлы; 2015 елның 15 апрелендәге 43-256 номерлы; 2018 елның 26 июнендәге 39-217 номерлы, 2023 елның 12 июлендәге 35-286 номерлы, 2024 елның 5 сентябрендәге 48-366 номерлы карарлар редакциясендә) (алга таба - Карар)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Яңа Чишмә» сәнәгать паркының күзәтү советы составы (3 нче кушымта).»;

1.2. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. «Яңа Чишмә» сәнәгать паркы резидентын «Унипарк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Яңа Чишмә» сәнәгать паркы администрациясе сыйфатында билгеләргә.»;

1.3. Карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендә булган территориядә урнашкан 16:31:150106:134 номерлары белән төзергә; 16:31:150106:153; 16:31:150106:156; 16:31:150106:157; 16:31:150106:165; 16:31:150106:387; 16:31:150106:392; 16:31:150106:393 кадастр номерлы гомуми мәйданы 81958,52 кв. м. булган «Яңа Чишмә» сәнәгать паркын төзергә.»;

1.4. карарга 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2013 елның 10 апрелендәге
22-148 номерлы карарына
3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советының түбәндәге
карарлары редакциясендә:
2015 елның 15 апрелендәге 43-256 номерлы;
2023 елның 12 июлендәге 35-286 номерлы;
2024 елның 23 октябрендәге 49-377 номерлы;)

«Яңа Чишмә» сәнәгать паркының күзәтү советы составы

| | | |
|---|---|---|
| Фасахов Ринат Рифгать улы | Күзәтү советы рәисе | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Исхакова Луиза Камил кызы | Күзәтү советы рәисе урынбасары | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) |
| Иванова Нина Николаевна | Күзәтү Советы секретаре | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге башлыгы |
| Попкова Надежда Ивановна | Күзәтү советы әгъзалары | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Габетдинов Ренат Хәлфәт улы | | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (инфраструктур үсеш буенча) |
| Шакиров Марат Хәйдәр улы | | «Унипарк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең генераль директоры (килешү буенча); |
| Попкова Наталья Владимировна | | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |